Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү авылында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 20 ноябре №4

“Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә,

“Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыру турында” 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктындагы халык җыены **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2020 елда һәр балигъ булган, теркәлгән урыны буенча

Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым акчасы түләтүне кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Ташкичү торак пунктында Ак каен урамында юл-урам челтәрен ремонтлауга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Ташкичү авыл җирлегенең рәсми стендларында, http://pravo.tatarstan рәсми мәгълүмат хокукый порталында, Ютазы муниципаль районының www.yutaza.tatar.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы: Р.К. Валеев.